ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**19.06.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1628**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 07 сентябрендәге 2176 номерлы карары белән(2021 елның 09 декабрендәге 3152 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 170 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 07 сентябрендәге 2176 номерлы карары белән (2021 елның 09 декабрендәге 3152 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына әлеге карарның кушымтасында каралганча үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигына «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре

порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе З.Ф. Хәбибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 19 июнендәге
1628 номерлы карарына
кушымта

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 07 сентябрендәге 2176 номерлы карары белән (2021 елның 09 декабрендәге 3152 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр

1. 1.2. пунктны түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Муниципаль хезмәт алучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба - мөрәҗәгать итүче), йә аларның вәкаләтле вәкилләре (алга таба - мөрәҗәгать итүче вәкиле).».

2. 3 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 3.8. һәм 3.9 бүлекчәләр белән тулыландырырга:

«3.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документның дубликатын бирү тәртибе, шул исәптән әлеге дубликатны бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

3.8.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документның дубликатын бирү процедурасын башлау өчен нигез булып муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документның дубликатын бирү турында гариза (алга таба - дубликат бирү турында гариза) керү тора (14 нче кушымта)

3.8.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документның дубликатын алу өчен мөрәҗәгать итүче булып муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге нәтиҗәсен элек алган зат тора. Мөрәҗәгать итүче исеменнән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документның дубликатын алуны Россия Федерациясе законнары нигезендә шундый хокукка ия булган , йә аңа мөрәҗәгать итүче тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тиешле вәкаләтләр бирелгән зат башкара ала.

3.8.3. Дубликат бирү турында гаризада түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

- Элек муниципаль хезмәт күрсәтелгән мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) ФИАт.и.;
- муниципаль хезмәт күрсәтүнең элек бирелгән нәтиҗәсен идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүмат.

3.8.4. Дубликат бирү турында гариза әлеге административ регламентның

2.5.8 пунктында күрсәтелгән ысуллар белән тапшырыла. Дубликат бирү турындагы гаризаны кабул итү һәм теркәү әлеге административ регламентның 2.13 пунктында каралган тәртиптә башкарыла.

3.8.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы белгеч, дубликат бирү турындагы гаризаны карау нәтиҗәләре буенча, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документның дубликатын бирү яки муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документның дубликатын бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

3.8.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документның дубликатын бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

- муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документның дубликатын бирү турындагы гаризада элек бирелгән документны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган мәгълүмат булмау;

-муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документның дубликатын бирү турында гаризаны вәкаләтле булмаган зат тапшыру.

3.8.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документның дубликатын бирү турында карар кабул итү критерие булып муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документның дубликатын бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең булмавы тора.

3.8.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документның дубликатын кабул итү, әзерләү яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документның дубликатын бирүдән баш тарту һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү өчен җаваплы белгечкә тапшыру, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы белгеч тарафыннан гариза теркәлгән көннән алып 3 эш көне эчендә башкарыла.

3.8.9. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документның дубликатын әзерләгәндә түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

- муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларның эчтәлеген үзгәртү;

- муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (рәсми мөрәҗәгать) биргәндә бирелмәгән яңа мәгълүмат, яңа алынган документлардан алынган белешмәләрне кертү.

3.8.10. Мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документның дубликатын бирү яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документның дубликатын бирүдән баш тарту, әлеге административ регламентның 2.3.2, 2.3.3 пунктларында билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3.8.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документның дубликатын яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документның дубликатын бирүдән баш тарткан факт, бирелгәннән соң архив исәбенә алынырга һәм сакланырга тиеш, Департаментта муниципаль

хезмәтләрне теркәү журналында язып куела.

3.8.12. Административ процедура нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

- муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документның дубликатын бирү;

- муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документның дубликатын бирүдән нигезле баш тарту.

### 3.9. Мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатен карамыйча калдыру тәртибе

3.9.1. Мөрәҗәгать итүче , муниципаль хезмәт күрсәтү срогы тәмамланган көнгә кадәрге эш көненнән дә соңга калмыйча, Башкарма комитетка муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен карамыйча калдыру турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы (15 нче кушымта).

3.9.2. Рәсми мөрәҗәгатьне карамыйча калдыру турында гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге административ регламентның 2.5.8 пунктында күрсәтелгән ысуллар белән тапшырыла.

3.9.3. Рәсми мөрәҗәгатьне карамыйча калдыру турында гаризаны кабул итү һәм теркәү әлеге административ регламентның 2.13 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.9.4. Рәсми мөрәҗәгатьне карамыйча калдыру турында гариза нигезендә Башкарма комитет муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатне карамыйча калдыру турында карар кабул итә һәм мөрәҗәгать итүчегә карарны , рәсми мөрәҗәгатьне карамыйча калдыру турында гариза кергән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча, җибәрә.

3.9.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне карамыйча калдыру, мөрәҗәгать итүченең хезмәт алу өчен Башкарма комитетка кабат мөрәҗәгать итүенә комачауламый.».».

3. Административ регламентны 14 нче кушымта һәм 15 нче кушымта белән тулыландырырга.

14 нче кушымта

Башкарма комитет
Җитәкчесенә___________________
______________________________
______________________________
______________________________

**Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документның дубликатын бирү турында гариза**

_________________________________________________________________
(хезмәт күрсәтүнең атамасы)

муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документның дубликатын бирүегезне сорыйм

Түбәндәге документларны беркетәм:

1.
2.
3.

Гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны:

электрон документны ___________________________E-mail адресына;

кәгазь чыганакта расланган күчермә рәвешендә почта аша ________________________________________________________________ адресына җибәрүегезне сорыйм.

Әлеге гаризага кертелгән, минем шәхесемә һәм мин тәкъдим иткән затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән белешмәләрнең дөрес булуын раслыйм. Гаризага кушып бирелгән документлар (документ күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза биргән вакытта бу документлар гамәлдә һәм төгәл белешмәләрне үз эченә ала.

_______________ __________________ ( _________________)
(дата) (имза) (Ф.И.Ат.и.)

15 нче кушымта

Башкарма комитет
Җитәкчесенә___________________
____________________
_______________________________
______________________________

Рәсми мөрәҗәгатьне карамыйча калдыру турында
ГАРИЗА

_________________________________________________ сәбәпләр буенча _____________________________________________________________________ гаризаны карамыйча калдыруыгызны сорыйм.

Мөрәҗәгать итүче_____________________________________________________________
(юридик затлар өчен - исеме, дәүләт теркәвенә алу номеры юридик затны бердәм дәүләт теркәвенә алу турында юридик затның юридик затлар реестрында һәм салым түләүченең идентификация номеры (мөрәҗәгать итүче чит ил юридик заты булган очраклардан тыш); физик затлар өчен - фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта), мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ реквизитлары (граждан өчен)

Мөрәҗәгать итүченең адресы: _____________________________________________________
(юридик затның урнашкан урыны; физик затның теркәлү урыны)

10) Мөрәҗәгать итүче белән элемтә өчен почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы______________________________________________________________________
__________________________________________________________________________.

Әлеге гаризага кертелгән, минем шәхесемә һәм мин тәкъдим иткән затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән белешмәләрнең дөрес булуын раслыйм. Гаризага кушып бирелгән документлар (документ күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза биргән вакытта бу документлар гамәлдә һәм төгәл белешмәләрне үз эченә ала.

| | | |
|---|---|---|
| _______________ | __________________ | ( __________________) |
| (дата) | (имза) | (Ф.И.Ат.и.) |